СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.08.2020 г. Заинск № 194

**«Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр булмаган белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 105 номерлы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Бюджет кодексы, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. "Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр булмаган белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында" 2018 елның 13 апрелендәге 105 номерлы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәр Советы карары белән расланган Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр булмаган белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.2 пунктына үзгәреш кертергә, «11163 сум» сүзләрен «11498 сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башлыгы урынбасары Е.В. Недошивинага йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**